**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Ребус» халыкара форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты төзү турында**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Ребус» халыкара форумын әзерләгәндә һәм уздырганда үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында **карар бирәм:**

1. Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Ребус» халыкара форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты төзергә.

2. Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Ребус» халыкара форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 08 февраль
№ 95

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2024 елның «08» февралендәге
95 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Ребус» халыкара форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Ребус» халыкара форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты (алга таба тиешенчә – Республика оештыру комитеты, Форум) – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының (алга таба – федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнары), Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының (алга таба – җирле үзидарә органнары), оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең Форумны әзерләгәндә һәм уздырганда үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында төзелгән коллегиаль орган.

2. Республика оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

## II. Республика оештыру комитетының төп бурычлары

3. Республика оештыру комитетының төп бурычлары:

а) Форумны әзерләү һәм уздыру буенча чараларның республика планын эшләү һәм раслау;

б) Форумны үткәрүне әзерләүгә бәйле планнарны, программаларны һәм аерым чараларны гамәлгә ашыру барышын анализлау, Форумны әзерләү һәм уздыру чараларының республика планын үтәүне һәм аны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны контрольдә тотуны тәэмин итү;

в) Республика оештыру комитеты кабул иткән карарларны гамәлгә ашыру барышында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнары территориаль

органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренең үзара хезмәттәшлеген оештыру буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү;

г) Форумны әзерләү һәм уздыру чараларының республика планын үтәүгә бәйле бурычларны хәл иткәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыру.

4. Республика оештыру комитеты үз алдында торган бурычларны гамәлгә ашыру максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән законнар нигезендә Республика оештыру комитеты компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

б) Республика оештыру комитеты компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә эш төркемнәре төзергә;

в) билгеләнгән тәртиптә үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләрен, аларның башка вәкилләрен һәм кызыксыну белдергән бүтән затларны чакырырга;

г) үз вәкилләрен Форумны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашырга җибәрергә.

## III. Республика оештыру комитеты составы

5. Республика оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

6. Республика оештыру комитеты составына Республика оештыру комитеты рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм Республика оештыру комитетының башка әгъзалары керә, алар аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнаша.

7. Республика оештыру комитеты рәисе булып Татарстан Республикасы Премьер-министры тора.

8. Республика оештыру комитеты рәисе (ул урынында булмаганда – рәис урынбасары):

а) Республика оештыру комитеты эшенә җитәкчелек итә, Республика оештыру комитеты утырышларында карала торган мәсьәләләр исемлеген, аларны карап тикшерү срокларын һәм тәртибен билгели;

б) утырышларның көн тәртибен, уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгели һәм раслый;

в) Республика оештыру комитеты утырышлары беркетмәләренә һәм башка документларына кул куя.

9. Республика оештыру комитеты секретаре:

а) Республика оештыру комитеты утырышларында катнаша;

б) Республика оештыру комитеты әгъзаларына утырышны уздыру көненә кадәр кимендә биш көн кала утырышны уздыру урыны, датасы, вакыты турында хәбәр итә, утырышның көн тәртибен җибәрә;

в) Республика оештыру комитеты утырышлары беркетмәләрен һәм башка документларын әзерләү өчен җавап бирә.

10. Республика оештыру комитеты әгъзалары:

а) Республика оештыру комитеты утырышларында шәхсән катнаша;

б) Республика оештыру комитеты компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча фикер алышуга тәкъдимнәр бирә;

в) Республика оештыру комитеты карарларын әзерләү, үтәү буенча башка чараларны гамәлгә ашыра.

## IV. Республика оештыру комитеты утырышлары һәм карарлары

11. Республика оештыру комитеты утырышлары кирәк булган саен, әмма кимендә кварталга бер тапкыр үткәрелә.

12. Республика оештыру комитеты утырышларын рәис яисә аның кушуы буенча рәис урынбасары алып бара.

13. Республика оештыру комитеты утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, эш алып барырга хокуклы дип санала. Республика оештыру комитеты карары, әгәр аның өчен утырышта катнашкан әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар саны тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Республика оештыру комитеты утырышында көн тәртибендәге мәсьәләләрне карап тикшерү һәм тавыш бирү йомгаклары буенча карарлар кабул ителә, алар беркетмә белән рәсмиләштерелә. Республика оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә рәислек итүче кул куя.

14. Республика оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынган органнарына, башкарма хакимиятнең территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый оешмаларга һәм берләшмәләргә, кызыксынган башка затларга эшчәнлек алып барганда куллану өчен җиткерелә.

## V. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген тәэмин итү

15. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник яктан, документлар, мәгълүмат белән һәм башкача тәэмин итүне Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы башкара.

---

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2024 елның «08» февралендәге
95 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Казан шәһәрендә ел саен үткәрелә торган «Ребус» халыкара форумын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Песошин<br>Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Республика оештыру комитеты рәисе |
| Айзатуллин<br>Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Миңнуллина<br>Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе, Республика оештыру комитеты секретаре |
| Агиев<br>Шамил Рәхим улы | «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы» Берлеге рәисе (килешү буенча) |
| Астафьев<br>Игорь Владимирович | «Казан Экспо» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Балтусова<br>Олеся Александровна | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе |
| Вахруков<br>Дмитрий Сергеевич | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министры урынбасары (килешү буенча) |
| Горбунов<br>Алексей Павлович | «Шәһәрне үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Григорьев Олег Дмитриевич | «Татарстан Республикасының кинлекләрне планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Иванов Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Коробченко Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Кудряшев Владимир Николаевич | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Лобов Андрей Николаевич | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Метшин Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Музыченко Сергей Григорьевич | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары (килешү буенча) |
| Низамов Рәшит Корбангали улы | «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Пахомов Сергей Александрович | депутат, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Савельев Игорь Леонидович | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Сибгатуллин Илдар Нурзадә улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе башлыгы |
| Толовенкова Дарья Валерьевна | «Татарстан Республикасының киңлекләрне планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждениесенең пассажир һәм транспорт юнәлешен үстерү бүлеге башлыгы |
| Финогенов Антон Владимирович | «ДОМ.РФ» акционер җәмгыятенең шәһәр мохитен үстерү буенча директоры (килешү буенча) |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Шадриков Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры |
| Шәйхетдинова Диана Олеговна | «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Шумаков Николай Иванович | «Россия Архитекторлар берлеге» гомумроссия иҗтимагый һөнәри иҗат оешмасы президенты (килешү буенча) |
| Яшенкова Мария Владимировна | «БМК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте башкарма директоры (килешү буенча) |

___________